**Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение**
**« Актанышская средняя общеобразовательная школа №1»**
**Актанышского муниципального района Республики Татарстан**

| «Рассмотрено» | “Согласовано» | “Утверждаю” |
|---|---|---|
| на ШМО учителей родного (татарского) языка и литературы<br>_________ Г.Ф.Рахманова<br>протокол №1<br>от «28 » августа 2023г. | Заместитель директора школы по ВР<br>___________ И.Н.Хуззятов<br>протокол от «29 » август2023г. | Директор школы<br>__________<br>А.М.Мансуров<br>приказ № 01-ОД<br>от «31» августа 2023 г. |

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ
СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП
Сертификат: 5DFFD1006FB0B0974A1C68BB022BFBB8
Владелец: Мансуров Альберт Мирхатович
Действителен с 31.08.2023 до 30.11.2024

# Кружок «Кызыклы грамматика»

**Составитель: Галиева Ленара Рафаиловна, учитель родного (татарского) языка и литературы высшей квалификационной категории.**

**2023-2024 учебный год**



Документ создан в электронной форме. № РП Кр 27 от 01.09.2023. Исполнитель: Мансуров А.М.
Страница 1 из 7. Страница создана: 23.10.2023 17:34
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

## Программаың эчтәлеге

### Сөйләм эчтәлеге

**Тыңлап аңлау.** Тыңланган текстның эчтәлегенә төшенү, аның буенча бирелгән сорауларга җавап бирү, әңгәмә үткәрү.

**Телдән сөйләм.** Сөйләм ситуациясенә бәйле рәвештә өйрәнгән тел берәмлекләрен куллана белү. Телнең орфоэпик һәм интонацион нормаларын саклап, диалогик һәм монологик сөйләмдә катнашу. Аерым темаларга караган сөйләм әдәбе үрнәкләрен дөрес файдалану.

**Уку.** Бирелгән текстның эчтәлеген аңлап, орфоэпик нормаларны саклап уку. Андагы җөмләләрне синтагмаларга бүлеп, сөйләм яңалыгын белдергән кисәкләргә логик басым ясап һәм йөгерек укый белү. Текстның темасын һәм төп фикерен билгеләү.

**Язу.** Грамотага өйрәтү чорында хәреф, аваз кушылмасы, иҗек, сүз һәм җөмлә язу. Өйрәнелгән кагыйдәләргә туры килә торган текстны әйтеп яздыру һәм күчереп язу. Укылган һәм тыңланган текстның эчтәлеген телдән яки язмача (сайлап) белдерү.

### Фонетика һәм орфоэпия

Сузык һәм тартык авазларны аеру. Сүзләрдә басымлы һәм басымсыз сузык авазларны табу. Нечкә һәм калын тартык авазларны аеру, парлы һәм парсыз тартык авазларны билгеләү. Яңгырау һәм саңгырау тартыкларны аеру, аларның парларын билгеләү. Авазларга характеристика бирү: сузык-тартык; басымлы-басымсыз; калын-нечкә сузыклар; яңгырау-саңгырау тартыклар. Сүзне иҗекләргә бүлү. Авазларның хәзерге әдәби тел нормаларына туры килгән әйтелеше. Сүз басымы. Сүзгә фонетик анализ элементлары.

### Графика

Аваз һәм хәрефне аеру. Язуда тартык авазларның калынлыгын һәм нечкәлеген билгеләү. Язуда калынлык (**ъ**) һәм нечкәлек (**ь**) билгеләрен куллану. **Е – ё**, **ю**, **я** хәрефләре булган сүзләрдә авазларны һәм хәрефләрне билгеләү. Сүзләр арасында буш урын калдыру, юлдан-юлга күчерү билгесе кую, абзац кебек график чараларны куллану. Алфавиттагы хәрефләрнең исемен, аларның урнашу тәртибен белү. Сүзлекләр, белешмәлекләр, каталоглар белән эшләгәндә, алфавиттан файдалана белү.

### Лексикология

Сүзне яңгыраш һәм мәгънә бердәмлеге буларак аңлау. Мәгънәсе төгәллек таләп итә торган сүзләрне барлау. Сүзнең мәгънәсен тексттан яки аңлатмалы сүзлек ярдәмендә билгеләү. Сүзнең бер һәм күп мәгънәле, туры һәм күчерелмә мәгънәле булуын, синоним һәм антонимнарның сөйләмдә кулланылышын күзәтү.

### Сүз төзелеше

Тамырдаш сүзләрне кабатлау. Аларны омонимнардан аеру. Сүз тамыры һәм кушымчаны билгеләү. Сүз ясагыч кушымчалар турында төшенчә бирү. Тамырдаш сүзләрнең төрле сүз ясагыч кушымчалар ярдәмендә ясалуы. Сүз составын тикшерү күнегүләре үтәү.

### Морфология

Сүз төркемнәрен кабатлау. Исем, аның мәгънәсе һәм сөйләмдә кулланылышы. Исемнәрнең сораулары. *Кем? Нәрсә?* сорауларына җавап биргән исемнәрне аеру. Ялгызлык һәм уртаклык исемнәрне таба белү. Исемнәрнең берлек һәм күплек сан формалары. Исемнәрнең килеш белән төрләнеше. Килеш сораулары. Исемнең тартым белән төрләнеше. Исемгә морфологик анализ ясау күнегүләре.

Сыйфат, аның мәгънәсе һәм сөйләмдә кулланылышы. Сыйфатның сораулары. Сыйфатның төрле (төс, форма, күләм, характер һ.б.) билгеләрне белдерүе. Сыйфатның исемгә бәйләнеп килүе. Сыйфат дәрәҗәләре. Сыйфатка морфологик анализ ясау.

Алмашлыкны кабатлау. Зат алмашлыклары, мәгънәсе һәм сөйләмдә кулланылышы. Берлек һәм күплек сандагы I, II, III зат алмашлыклары, аларның килеш белән төрләнеше.

Фигыль, аның мәгънәсе һәм сөйләмдә кулланылышы. *Нишли? Нишләде? Нишләр?* сорауларына җавап биргән фигыльләрне аеру. Фигыльнең зат-сан белән төрләнүе. Аның төрле заман формалары (хәзерге, үткән, киләчәк заманнар). Фигыльнең барлыкта һәм юклыкта килүе. Фигыльгә морфологик анализ ясау.

Рәвеш, аның мәгънәсе, сораулары һәм сөйләмдә кулланылышы.

Бәйлекләр, аларның сөйләмдәге әһәмияте.

Кисәкчәләр (*да*, *дә*, *та*, *тә*, *гына*, *генә*, *кына*, *кенә*, *ук*, *үк*, *ич*, *бит*). Аларның дөрес язылышы.

### Синтаксис



Документ создан в электронной форме. № РП Кр 27 от 01.09.2023. Исполнитель: Мансуров А.М.
Страница 2 из 7. Страница создана: 23.10.2023 17:34
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Сүз, сүзтезмә һәм җөмләләрне аеру, аларның аермалы якларын аңлау. Әйтү максаты ягыннан хикәя, сорау, боеру, тойгылы җөмләләр һәм аларны дөрес интонация белән уку, алардан соң тыныш билгеләрен кую.

Җөмлә. Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләре турында төшенчә. Сүзтезмәдәге сүзләр һәм җөмлә кисәкләре арасында мәгънә бәйләнешен сораулар ярдәмендә ачыклау.

Теркәгечле (*һәм*, *ә*, *ләкин*) һәм теркәгечсез тиңдәш кисәкле җөмләләрне табу һәм мөстәкыйль төзү. Тиңдәш кисәкле җөмләләрдә санау интонациясе.

Гади һәм кушма җөмләләрне аеру.

**Орфографик һәм пунктуация.** Орфографик зирәклек тәрбияләү.

Дөрес язу кагыйдәләрен куллану:

– сузык аваз хәрефләрен дөрес язу кагыйдәләре;
– тартык аваз хәрефләрен дөрес язу;
– сүзне юлдан-юлга күчерү;
– җөмлә башындагы беренче сүзне һәм ялгызлык исемнәрне баш хәреф белән язу;
– калынлык (ъ) һәм нечкәлек (ь) билгеләре;
– һәмзә [ ’ ] авазын белдерү;
– җөмлә ахырында нокта, сорау һәм өндәү билгеләре;
– тиңдәш кисәкле җөмләләрдә өтер кую.

**Сөйләм үстерү.** Аралашу ситуациясен – аралашу кем белән, кайда, нинди максат белән башкарылуын аңлау. Үз фикереңне әйтү һәм аны дәлилләү. Әңгәмә үткәрүнең төп күнекмәләрен үзләштерү (сүз башлау, әңгәмәгә кушылу, аны дәвам итү, игътибарны җәлеп итү һ.б.). Уку, көндәлек аралашу шартларында сөйләм әдәбе нормаларын үзләштерү (сәламләү, хушлашу, гафу үтенү, рәхмәт әйтү, сорау белән мөрәҗәгать итү). Татар телен йомшаграк белүче кешеләр белән аралашканда сөйләм әдәбе үзенчәлекләре.

Аерым темага караган сөйләм текстлары (сурәтләү яки хикәяләү формасында) кулланып, телдән монологик сөйләм оештыру.

Текст. Текст билгеләре. Тексттагы җөмләләрнең мәгънә бердәмлеге. Текстка исем бирү. Тексттагы җөмләләрнең эзлеклелеге. Текст кисәкләренең (өлешләренең) эзлеклелеге (абзац).

Текст буенча комплекслы эш: аңа исем бирү, җөмлә һәм текст кисәкләренең эзлеклелеген аңлау.

Текст планы. Бирелгән текст буенча план төзү яки бирелгән план буенча үз текстыңны төзү.

Текст типлары: сурәтләү, хикәяләү формасындагы текстлар. Аларның үзенчәлекләре.

Котлау тексты һәм хат язу. Язма сөйләмнең төгәллеген, дөреслеген һәм сәнгатьлелеген саклап, аерым текстлар төзү һәм бирелгән текстларны тикшерү, төзәтү; текстта синонимнар, антонимнар куллану.

Изложение һәм сочинениенең төп төрләре белән танышу (билгеләмәләрен ятламыйча): бирелгән текстны тулысынча яки аерым файдаланып, төрле урыннарын (сүзләрен) сайлап языла торган изложение, сочинение элементлары булган изложение, хикәяләү-сурәтләү рәвешендәге сочинение.

Гамәли дәресләрдә укучылар белән төркемләп, парлап һәм индивидуаль эш төрләрен куллану отышлы. Формаларның төрлелеге дәресләрне кызыклы итү белән беррәттән, текст анализлау, укучыларның дөрес язу күнекмәләрен камилләштерүгә дә ярдәм итәчәк. Шул нигездә укучылар укытучы ярдәмендә төрле авырлыктагы материаллар белән индивидуаль эш планы төзи ала.

## Программаны үзләштерүдән көтелгән нәтиҗәләр

-укучылар телнең милли мәдәниятькә каравын, аның төп аралашу чарасы булуын аңлый;
-әдәби нормаларга туры килгән телдән һәм язма сөйләмгә ия булган кешегә уңай мөнәсәбәт тәрбияләнә, аның культуралы шәхес булуы аңлатыла;
-татар теленең орфоэпик, лексик, грамматик нормалары һәм сөйләм әдәбе турында мәгълүмат бирелә, аралашу өчен кирәкле тел материалын сайлап кулланырга өйрәтә;
-татар теле буенча алган белемнәрне укучы танып-белү һәм аралашу өчен тиешенчә куллана белә.
тел һәм сөйләм төрләрен классификацияләү, активлаштыру;
-текстны дөрес эшкәртү алымнарын файдалану;
-дөрес, камил сөйләм төзүгә ирешү;



Документ создан в электронной форме. № РП Кр 27 от 01.09.2023. Исполнитель: Мансуров А.М.
Страница 3 из 7. Страница создана: 23.10.2023 17:34
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

**Программаны үзләштерү нәтиҗәсендә, укучылар түбәндәгеләрне өйрәнә:**

-Россия Федерациясендәге телләр һәм мәдәниятләрнең күп төрле булуы турында мәгълүмат ала, телнең милли үзаңны белдерүгә нигез булуын күзаллый;
-укучыларда телдән һәм язма сөйләмне дөрес итеп төзүгә уңай караш тәрбияләнә, алар аны шәхеснең тәрбияле булу билгесе итеп кабул итә;
-туган телдә (татар телендә) орфоэпик, лексик һәм грамматик төшенчәләрне, сөйләм әдәбе кагыйдәләрен үзләштерә, аралашуның максат һәм бурычларыннан чыгып, тиешле тел берәмлекләреннән урынлы итеп файдалана белә;
-аралашу вакытында өйрәнелгән тел берәмлекләрен танып-белү һәм гамәли максатлардан чыгып файдалана.

**Укучылар өчен ия булырга тиешле белем, осталык һәм күнекмәләр**

1. Туган телне өйрәнү өчен шартлар булдыру;
2. Уку-укыту процессында укучыны аңлап һәм актив рәвештә белем алуга әзерләү, алган белемнәрен, осталыкларын, күнекмәләрен ныгыту;
3. Туган тел буенча системалы фәнни белем бирү, аларны ирекле аралашырга өйрәтү, татар дөньясы турында күпкырлы мәгълүмат җиткерү;
4 . Укучыларны тестлар белән эшләргә өйрәтү;
5. Теленең үсеш үзенчәлекләрен төгәл күз алдына китерү, тел үсеп торсын өчен, аның көндәлек кулланышын тәэмин итү юлларын белү;
6. Төрле стильләрне аера белү, алардан файдалана белү;
7. Сүзлекләрнең төрләрен, төзелешен белеп, алардан иркен файдалана алу;
8. Укучыларның телләр белү дәрәҗәләрен камилләштерү, үстерү.

**Төп максатлары:**

**-** укучыларның фонетик, орфоэпик, орфографик, лексик, грамматик нигезләреннән алган белемнәрне системалаштыру, катлаулырак формаларда өйрәтүне дәвам итү;
- телнең төп грамматик чараларын язма һәм телдән сөйләм процессында куллануга ирешү;
- укучыларның иҗади һәм мөстәкыйль фикерли алу мөмкинлекләрен үстерү, үз фикерләрен дәлилли белергә күнектерү;
- татар әдәби тел нормаларын һәм стилистик мөмкинлекләрен ачык күзаллауга , аларны тиешенчә куллана белергә өйрәтү;
- телне тулы бер система буларак күзаллау;
- текст һәм башка мәгълүмати чаралар белән эшләү, аннан кирәкле мәгълүматны таба белү һәм аны тиешенчә үзгәртә алу күнекмәләрен үстерү;
- укучыларның орфографик һәм пунктуацион грамоталылыгын камилләштерү.

**бурычлары:**

1) укучыларның игътибарын телнең эстетик функциясен чагылдыручы әдәби текстка, өйрәнелә торган тел күренешләренең сәнгатьлелек ягына юнәлтү;
2) балалар туган телнең матурлыгын күрергә һәм ишетергә өйрәнсеннәр, нинди сурәтләү чаралары аша аның тормышка ашырылуын аңласыннар өчен телнең тасвирлау һәм сурәт ясау мөмкинлекләрен күрсәтү, телнең җанлы халәтен, кулланылыш рәвешен өйрәнеп, сүз белән сөйләм арасындагы бәйләнешнең нигезенә ныграк төшенергә , әдәби әсәрдә һәм автор сөйләмендә сүзнең тәмен, ямен, матурлыгын тоярга, үз сүзен, фикерен әйтә белергә өйрәтү.
3)әдәби тел нормаларын күнекмәләрдә дөрес куллана алуга өйрәтү, иҗадилыкка омтылу
4) Текстны комплекслы анализлау күнекмәләрен булдыру.
5) Инша һәм изложение язу күнекмәләрен камилләштерү.

Программаны үзләштерү нәтиҗәләрен тикшерү формалары:
- өйрәнгән материал буенча тест эше үткәрү;



Документ создан в электронной форме. № РП Кр 27 от 01.09.2023. Исполнитель: Мансуров А.М.
Страница 4 из 7. Страница создана: 23.10.2023 17:34

- кыска изложение язу;
- аерым бер темага инша язу.

## КАЛЕНДАРЬ-ТЕМАТИК ПЛАН

| № | Дәреснең темасы | Срок | Үтәлеш |
|---|---|---|---|
| 1 | Аерым темалар буенча тест эшләү (исем, сыйфат, фигыльх.б.) | 5.09 | |
| 2 | 1) Җөмләләрнең баш кисәкләрен таба белү.<br>2) Исемнәрнең килешләрен дөрес билгеләү күнекмәләре булдыру.<br>3) Аваз һәм хәрефләре туры килмәгән сүзләрнең транскрипциясен яза белү күнекмәләре булдыру | 12.09 | |
| 3 | Язуда тартык авазларның калынлыгын һәм нечкәлеген билгеләү. | 19.09 | |
| 4 | 1) орфография кагыйдәләрен кабатлау.<br>2) Исемнәрнең килешләрен дөрес билгеләү күнекмәләре булдыру. | 26.09 | |
| 5 | Сүз төркемнәрен дөрес билгеләү күнекмәләре булдыру | 3.10 | |
| 6 | Олимпиада биремнәре белән эш, хаталарны төзәтү | 10.10 | |
| 7 | 1.Сүз төркемнәрен дөрес билгеләү күнекмәләре булдыру.<br>2. Фигыльләргә төркемчәләрен, юнәлешләрен билгеләргә өйрәтү | 17.10 | |
| 8 | 1 Бәйлекләр, аларның сөйләмдәге әһәмияте.<br>2. Фигыльләргә морфологик анализ | 24.10 | |
| 9 | 1.Җөмләләрнең баш кисәкләрен таба белү.<br>2. Исемнәрнең килешләрен дөрес билгеләү күнекмәләре булдыру.<br>4)Фигыльләргә төркемчәләрен билгеләргә өйрәтү | 7.11 | 2ч |
| 10-11 | 1.Текст белән эш.Сүзләрнең мәгънәле кисәкләрен (тамыр, сүз ясагыч кушымча, модаль кушымча, бәйләгеч кушымча) табу күнекмәләре булдыру | 14.11<br>21.11 | |
| 12 | 1 Җөмләләргә синтаксик анализ ясау | 28.11 | |
| 13 | Сүз төркемнәрен дөрес билгеләү, ныгыту | 5.12 | |
| 14 | Хәбәрлек сүзләр | 12.12 | |
| 15 | 1.Сингармонизм законы. Ирен һәм рәт гармониясе | 19.12 | |
| 16 | Саннарның төркемчәләрен билгеләү. Язудагы роле | 26.12 | |
| 17 | 1.Текст белән эш. Әйтелеше белән язылышы туры килмәгән сүзләрне таптыру күнекмәләре булдыру. | 9.01 | 3ч |
| 18 | Сыйфатлар таптыру. Текст белән эш. Асыл һәм нисби сыйфатлар | 16.01 | |
| 19 | 1. Текст белән эш. Алгы рәт сузыкларыннан гына торган сүзләрне таптыру. | 23.01 | |
| 20 | Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр | 30.01 | |
| 21 | Тартым кушымчалары. | 6.02 | |
| 22 | Тартым белән төрләнгән исемнәрне таба белү күнекмәләре | 13.02 | |
| 23 | Тексттан алынма сүзләр, ялгызлык исемнәр таптыру. | 20.02 | |
| 24 | Иҗади сүзлек диктанты | 27.02 | |
| 25 | Синоним, антоним, омонимнар | 5.03 | |
| 26 | Фигыль. Фигыльләрнең төркемчәләрен, заманнарын, затларын билгеләү күнекмәләре | 12.03 | |
| 27 | Олимпиада биремнәре. | 19.03 | |



Документ создан в электронной форме. № РП Кр 27 от 01.09.2023. Исполнитель: Мансуров А.М.
Страница 5 из 7. Страница создана: 23.10.2023 17:34
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| | | | |
|---|---|---|---|
| 28 | 1. Тексттагы тыныш билгеләренең куелышына бәйле кагыйдәләрне кабатлаттыру.<br>2. Җөмләдәрнең грамматик нигезен таптыру күнекмәләре булдыру. | 2.04 | 4ч |
| 29-30 | Синтаксис. Гади җөмләлә синтаксисы | 9.04<br>16.04 | |
| 31 | 1. Сүз төркемнәре<br>2. Җөмләдәрнең грамматик нигезен таптыру күнекмәләре булдыру. | 23.04 | |
| 32 | Сан төркемчәләру | 30.04. | |
| 33 | Сүз ясалышы ысуллары | 7.05 | |
| 34 | Кабатлау, йомгаклау | 14.05,<br>21.05 | |



Документ создан в электронной форме. № РП Кр 27 от 01.09.2023. Исполнитель: Мансуров А.М.
Страница 6 из 7. Страница создана: 23.10.2023 17:34
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Лист согласования к документу № РП Кр 27 от 01.09.2023
Инициатор согласования: Мансуров А.М. Директор
Согласование инициировано: 23.10.2023 17:34

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Мансуров А.М. | | Подписано<br>23.10.2023 - 17:34 | - |



ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН